# КАРАР

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлегенең Урта Мишә торак пунктының гражданнар җыены буенча

**2019 елның 16 ноябре, Урта Мишә авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә, 2019 елның 16 ноябрендә Урта Мишә торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлегенең Урта Мишә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 2000 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- койманы ремонтлау өчен металл әйберләр сатып алу,зират коймасын ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү (профиль, профнастил) - 1,5 м.)

- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;

Мәскәү урамында Бөек Ватан сугышы ветераннары хөрмәтенә обелиск төзү;

- юлларны кардан чистарту

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 105 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 62 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында катнашкан 62 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлегенең Урта Мишә торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлегенең Урта Мишә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 2000 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- койманы ремонтлау өчен металл әйберләр сатып алу,зират коймасын ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү (профиль, профнастил 1,5 м.)

- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;

Мәскәү урамында Бөек Ватан сугышы ветераннары хөрмәтенә обелиск төзү;

- юлларны кардан чистарту - кабул ителгән.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында әлеге карарны Баландыш авыл җирлегенең Интернет челтәрендә рәсми сайтында, мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Баландыш авыл җирлеге Башлыгы: Р. Ш. Мөхәмәтшин